нәтиҗәләре төрлечә булган. Мәгълүматларга таянып, кайсы укучы дөрес нәтиҗә чыгарган?

**1)** Екатерина: «Атлантик океанга якынайган саен, кышлар җылырак».

**2)** Виктор: «Көнбатыштан көнчыгышка хәрәкәт иткәндә, җәйләр җылырак».

**3)** Даниил: «Атлантик океаннан ерагайган саен, атмосферадагы явым-төшемнең уртача еллык күләме арта».

**4)** Арина: «Җәй җылырак булган саен, елның бу фасылында атмосфера явым- төшемнәре күбрәк булу күзәтелә.

719. Торак пунктларның кайсында 22 нче июньдә Кояш Мәскәү вакыты белән горизонт өстенә барысына караганда иртәрәк күтәрелә?

**1)** Париж

**2)** Мюнхен

**3)** Мишкольц

**4)** Черновцы




720. Һава торышы картасы 2010 нчы елның 12 нче апреленә төзелгән. Картада күрсәтелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне суытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Пермь

**2)** Сыктывкар

**3)** Омск

**4)** Төмән

721. Картада күрсәтелгән шәһәрләрнең кайсы антициклон зонасында?

**1)** Архангельск

2) Салехард

3) Ростов-Дон

4) Мәскәү

722. Укучылар интернеттан Европада бер үк параллельдә, ләкин төрле меридианнарда яткан пунктларның климаты турында мәгълүматлар туплаганнар. Бу мәгълүматларны җирле метеостанцияләр күпьеллык күзәтүләренә нигезләнеп биргәннәр. Укучылар тарафыннан тупланган әлеге мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

| Күзәтү пункты | Пунктның географик координатлары | Һаваның уртача температурасы, °С | | Атмосферадагы явым-төшемнәр, норма, мм | | Атмосфера явым-төшемнәренең уртача еллык күләме, мм |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | январь | июль | январь | июль | |
| Шалон | 48° т.к. 4° көнч.о. | +2,2 | +18,5 | 48 | 61 | 629 |
| Мюнхен | 48° т.к. 11° көнч.о. | +0,5 | +19,3 | 48 | 127 | 928 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Кошице | 48° т.к. 21° көнч.о. | –3,4 | +19,2 | 28 | 85 | 612 |
| Черновцы | 48° т.к. 26° көнч.о. | –4,9 | +19,1 | 27 | 94 | 632 |

Укучылар туплаган әлеге мәгълүматларын, климатик үзенчәлекләр белән географик урыны арасындагы бәйлелекне ачыклау максаты белән анализлап чykканнар Укучыларның нәтиҗәләре төрлечә булган. Мәгълүматларга таянып, кайсы укучы дөрес нәтиҗә чыгарган?

1) Олег: «Атлантик океаннан ерагайган саен, атмосферадагы явым-төшемнең уртача еллык күләме арта».

2) Филипп: «Көнбатыштан көнчыгышка хәрәкәт иткәндә, җәйләр җылырак».

3) Анастасия: «Атлантик океаннан ерагайган саен, кышлар салкынрак була бара».

4) Диана: «Кыш җылырак булган саен, елның бу фасылында атмосфера явым-төшемнәре күбрәк булу күзәтелә».

723. Торак пунктларның кайсында 22 нче июньдә Кояш Мәскәү вакыты белән горизонт өстенә барысына караганда соңрак күтәрелә?

1) Шалон

2) Мюнхен

3) Кошице

4) Черновцы

---

724. Атлантик океан ярлары буендагы тропик киңлекләрдә дөньяның иң коры чүлләренең берсе Намиб урнашкан, Намибия дәүләтенә исем дә шуннан чыгып бирелгән. Монда атмосфера яаым-төшемнәренең бер еллык уртача күләме 15 мм дан артмый. Метеокүзәтүләр тарихы бу чүлдә хәтта 20 ел дәвамында бер тамчы яңгыр яумауны теркәгән.

Намиб чүлендә атмосферада явым төшүләр булмау нәрсә белән аңлатылыр? Ике сәбәбенә тукталыгыз.

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

725. Россиянең берничә торак пунктынад яшәүче укучылар җирле метеостанцияләрнең күпьеллык күзәтүләре мәгълүматлары белән алмашканнар. Укучылар тарафыннан тупланган әлеге

мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

| Күзәтү пункты | Пунктның географик координатлары | Диңгез өсте тигезлегеннән биеклеге, м | Һаваның уртача температурасы, °С | | Атмосфера явым-төшемнәренең уртача еллык күләме, мм |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | июль | январь | |
| Псков | 57° т.к. 28° көнч.о. | 42 | +17,4 | – 6,9 | 628 |
| Иваново | 57° т.к. 41° көнч.о. | 111 | +18,4 | – 9,5 | 611 |
| Балахна | 57° т.к. 44° көнч.о. | 63 | +19,0 | –11,6 | 542 |
| Ижевск | 57° т.к. 53° көнч.о. | 155 | +18,7 | –13,5 | 532 |

Укучылар туплаган әлеге мәгълүматларын, климатик үзенчәлекләр белән географик урыны арасындагы бәйлелекне ачыклау максаты белән анализлап чыкканнар Укучыларның нәтиҗәләре төрлечә булган. Мәгълүматларга таянып, кайсы укучы дөрес нәтиҗә чыгарган?

1) Алексей: «Россиянең Европа өлешендә һава температурасы

январьдә көньяктан төньякка таба барганда түбәнәя».

**2)** Анна: «Россиянең Европа өлешендә һава температурасы январьдә көнбатыштан көнчыгышка барган саен түбәнәя».

**3)** Пётр: «Торак пункт диңгез өслегеннән никадәр түбәнрәк урнашса, атмосферада явым-төшемнәр шуның кадәр күбрәк».

**4)** Светлана: «Торак пунктның диңгез өслегеннән биеклеге арткан саен һава температурасы январьда түбәнәя».

726. Торак пунктларның кайсында 21 нче мартта Кояш, Мәскәү вакыты белән, горизонт өстенә барысына караганда соңрак күтәрелә?

**1)** Балахна

**2)** Иваново

**3)** Псков

**4)** Ижевск




727. Һава торышы картасы 2010 нчы елның 15 нче мартына төзелгән. Картада күрсәтелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне суытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Екатеринбург

**2)** Санкт-Петербург

**3)** Мәскәү

**4)** Петрозаводск

728. Шәһәрләрнең кайсы антициклон хөкем иткән зонада?

**1)** Ростов-Дон

**2)** Екатеринбург

**3)** Мәскәү

**4)** Петрозаводск

729. Атласның климатик карталарына нигезләнеп, кайсы шәһәрнең климаты **Z** климатограммасында чагылыш табуын билгеләгез.

**1)** Оренбург

**2)** Владивосток

**3)** Калининград

**4)** Чита

730. Рәсемдә Евразиядә урнашкан якынча бер үк киңлектә һәм диңгез өсте тигезлегеннән бер үк биеклектә булган ике шәһәр өчен төзелгән **X** һәм **Z** климатограммалары бирелгән. Шәһәрләрнең кайсы көнчыгыштарак урнашкан – **X** яки **Z?**

Җавабыгызны нигезләгез, ике дәлил китерегез.

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта биремнең номерын бирегез.




731. Һава торышы картасы 2011 нче елның 1 нче февраленә төзелгән. Картада күрсәтелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне суытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Мәскәү

2) Түбән Новгород

3) Оренбург

4) Омск

732. Шәһәрләрнең кайсы антициклон хөкем иткән зонада?

1) Мәскәү

2) Түбән Новгород

**3)** Санкт-Петербург

**4)** Элиста

**Климатограмма А** **Климатограмма Б**

t°C Осадки, мм t°C Осадки, мм







733. Атласның климатик карталарына нигезләнеп, кайсы шәһәрнең климаты **А** климатограммасында чагылыш табуын билгеләгез.

**1)** Астрахань

**2)** Мурманск

**3)** Калуга

**4)** Сочи

734. Рәсемдә Евразиядә урнашкан, якынча бер үк киңлектә һәм диңгез өсте тигезлегеннән бер үк биеклектә булган ике шәһәр өчен төзелгән **А** һәм **Б** климатограммалары бирелгән. Шәһәрләрнең кайсы көнчыгыштарак урнашкан – **А** яки **Б?**

Җавабыгызны нигезләгез, ике дәлил китерегез.

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта биремнең номерын бирегез.



735. Шәһәрләрнең кайсы антициклон хакимлек иткән зонада?

1) Мәскәү

2) Түбән  Новгород

3) Новосибирск

4) Санкт- Петербург

736. Һава торышы картасы 2010 нчы елның 13 нче маена төзелгән. Картада күрсәтелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне суытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Воронеж

2) Сыктывкар

3) Мәскәү

4) Петрозаводск




737. Һава торышы картасы 7 нче майга төзелгән. Торак пунктларның кайсында икенче көнне шактый нык җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Салехард

**2)** Томск

**3)** Якутск

**4)** Ямбург

738. Шәһәрләрнең кайсы циклон хакимлек иткән зонада?

**1)** Иркутск

**2)** Чита

**3)** Улан-Удэ

**4)** Ямбург

**Климатограмма X** **Климатограмма Z**







739. Рәсемдә Евразиядә урнашкан, якынча бер үк киңлектә һәм диңгез өсте тигезлегеннән бер үк биеклектә булган ике шәһәр өчен төзелгән **X** һәм **Z** климатограммалары бирелгән. Шәһәрләрнең кайсы көнчыгыштарак урнашкан – **X** яки **Z?** Җавабыгызны нигезләгез, ике дәлил китерегез.

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

740. Атласның климатик карталарына нигезләнеп, Кайсы

шәһәрнең климаты **X** климатограммасында чагылыш табуын билгеләгез.

**1)** Ростов-Дон

**2)** Петрозаводск

**3)** Сыктывкар

**4)** Архангельск

---




741. А пункты өчен һава температурасының бер еллык уртача айлык амплитудасын билгеләгез. Җавабыгызны сан белән языгыз.

742. Климатограмма мәгълүматларына нигезләнеп, А пункты климаты турындагы дөрес раслауны билгеләгез.

**1)** Ноябрь һәм декабрьдә атмосфера явым-төшемнәренең 11 мм га якыны ява.

**2)** Октябрьдә һаваның уртача температурасы 0°С тан артык.

**3)** Февральдәге явым-төшемнәр май аендагыдан күбрәк.

**4)** Һаваның апрельдәге уртача айлык температурасы сентябрьнекеннән югарырак.

---

743. Көчле җир тетрәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир шуышулар Папуа-Яңа Гвинея дәүләтенә караган Сөләйман (Соломон) утравында яшәүче меңгә якын кешене йортсыз-җирсез калдырган. Архипелагның көньяк-көнбатыш өлешендә 70 км тирәнлектә 6,8 магнитудалы җир асты селкетүләре була. Аерым районнарда масштаблы җимерелүләр булса да, кешеләрнең һәлак булулары турында хәбәрләр алынмый.

Ни өчен Сөләйман (Соломон) утравы территорияләрендә җир тетрәү ихтималы зур?

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта

биремнең номерын  бирегез.

744. Кайсы дәүләтнең территориясендә җир тетрәү ихтималы зуррак ?

1) Ангола
2) Финляндия
3) Швеция
4) Чили

745. Без Урта диңгездән Бискайя култыгы ярларына кадәр юлны уздык. Менә, ниһаять, без сәяхәтебезнең соңгы пункты булган Ла-Рошель шәһәрендә. Монда сәяхәт итеп кайта торган яхталар порты бар. Тар гына урамнар буйлап портка килеп җитәбез. Җылы җәйге көн. Диңгез өстендә җиңелчә җил (бриз) исә. Култыкның өсте яхталар белән шыгырым тулы.

Көндезге җил (бриз) кайсы юнәлештә исә, һәм алар ни өчен океан яр буенда ясалалар?

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

746. Текстта сурәтләнгән Ла-Рошель шәһәренең географик урынын кайсы илнең картасыннан ачыкларга мөмкин?

**1)** Төркия

**2)** Греция

**3)** Франция

**4)** Италия

747. Россиянең кайсы шәһәрләре өчен диңгез бризы характерлы?

**1)** Чита

**2)** Псков

**3)** Новороссийск

**4)** Челябинск




748. Климатограмма мәгълүматларына таянып, А пункты климаты турындагы дөрес раслауны билгеләгез.

**1)** Кышкы айларның иң салкыны – январь.

**2)** Явым-төшемнәрнең уртача күләме 150 мм.

**3)** Май аеның уртача айлык һава температурасы, гадәттә, +12°С тан югарырак.

**4)** Февраль һәм декабрь айларында явым-төшем күләме тигез.

749. А пункты өчен һава температурасының бер еллык уртача айлык амплитудасын билгеләгез. Җавабыгызны сан белән языгыз.

750. Россиянең берничә торак пунктында яшәүче укучылар җирле

метеостанцияләрнең һаваның июль һәм январь айларындагы уртача температурасы һәм башка климатик күрсәткечләре турындагы күпьеллык күзәтүләре мәгълүматлары белән алмашканнар. Укучылар тарафыннан тупланган әлеге мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

| Күзәтү пунктлары | Күзәтү пунктларының географик координаталары | Диңгез өсте тигезлегеннән биеклеге, м | Һаваның уртача температурасы, °С | | Атмосфера явым-төшемнәренең уртача еллык күләме, мм |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | январь | июль | |
| Вологда | 59° т.к. 40° көнч.о. | 107 | –11 | +18 | 540 |
| Пермь | 58° т.к. 56° көнч.о. | 171 | –14 | +18 | 570 |
| Краснотурьинск | 60° т.к. 60° көнч.о. | 201 | –15 | +18 | 518 |
| Нижневартовск | 61° т.к. 77° көнч.о. | 52 | –17 | +18 | 442 |

Укучылар туплаган әлеге мәгълүматларын климатик үзенчәлекләр белән географик урыны арасындагы бәйлелекне ачыклау максаты белән анализлап чыкканнар Укучыларның

нәтиҗәләре төрлечә булган. Мәгълүматларга таянып, кайсы укучы дөрес нәтиҗә чыгарган?

**1)** Ангелина: «Торак пункт биектәрәк урнашкан саен, анда январь салкынрак».

**2)** Аркадий: «Атмосферадагы явым-төшемнәрнең уртача еллык күләме көнбатыштан көнчыгышка кими».

**3)** Дарья: «Торак пункт биектәрәк урнашкан саен, анда атмосферадагы явым-төшемнәрнең уртача еллык күләме зуррак».

**4)** Олег: «Һаваның уртача температурасы январьда көнбатыштан көнчыгышка барган саен түбәнәя».

751. Кояш кайсы шәһәрдә 21 нче мартта горизонт өстенә Мәскәү вакыты буенча барысына караганда да иртәрәк күтәрелә?

**1)** Вологда

**2)** Пермь

**3)** Краснотурьинск

**4)** Нижневартовск

752. Ямал ярымутравы – Россиянең стратегик иң мөһим нефть һәм газга бай регионнарының берсе. Мәңгелек туң һәм территориясенең сазлыклы булуы, шулай ук Ямалның экологиясенә карата сакчыл мөнәсәбәт булдыру ихтыяҗы, файдалы казылмаларны чыгарганда, уникаль технологияләрдән файдалануга сәбәпче булалар.

Ямалның сазлыклануына күпьеллык туң тәэсир итә. Ямалда сазлыклар һәм сазлыкланган җирләр булуга тагын нәрсәләр тәэсир иткән? Климатик үзенчәлекләргә бәйле бер һәм территориясенең рельеф үзенчәлекләренә бәйле тагын бер сәбәбен атагыз.

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

753. Кояш батареяләренең кайберләре бер урынга урнаштырылган һәм билгеле бер хәлдә ныгытылган күпләгән батынкы көзгеләрдән торалар. Севилья (Испания) шәһәрендә кояш энергиясе җайланмасы 600 дән артык көзгедән торып, электроэнергиясе белән 6000 артык йортны тәэмин итә. Җир өслегенә килеп җитә торган кояш радиациясе күләме сезонга бәйле үзгәрә һәм пунктның географик киңлегенә бәйле.

Севилья шәһәренең урнашу урынын билгеләү өчен кайсы

картадан файдаланырга кирәк?

1) Европа

2) Азия

3) Африка

4) Көньяк Америка

754. Испаниядә җир өслегенең 1 $м^2$ килә торган кояш радиациясе күләме елның кайсы вакытында һәм ни өчен иң югары?

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

755. Тын океан муссоннары Кытайның төньяк-көнчыгыш районнарына көчле яңгырлар алып килгән. Атмосфера явым-төшемнәренең гомуми күләме әлеге ел фасылы өчен гадәти булган нормадан 2 тапкырга артып китә. Ляонин провинциясендә елгалар ярларыннан чыга. Кайсыбер авылларга су астында калу куркынычы яный.

Кытайның төньяк-көнчыгыш районнарында атмосфера явым-төшемнәренең уртача еллык күләмен билгеләү өчен санап кителгән карталарның кайсын сайларга кирәк?

1) физик

2) геологик

3) климатик

4) табигый зоналар

756. Муссоннар елның кайсы вакытында һәм ни өчен Кытайның төньяк-көнчыгыш районнарында океаннан материкка таба исәләр.

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта биремнең номерын бирегез.




757. Һава торышы картасы 8 нче мартка төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый нык җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Төмән

2) Томск

3) Витим

4) Чита

758. Картада бирелгән торак пунктларның кайсы антициклон хакимле киткән зонада?

1) Дудинка

**2)** Салехард

**3)** Улан-Удэ

**4)** Ямбург




759. Һава торышы картасы 2012 нче елның 30 нчы декабренә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый нык суытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Оренбург

**2)** Сыктывкар

**3)** Санкт-Петербург

4) Воронеж

760. Картада бирелгән торак пунктларның кайсы антициклон хакимлек иткән зонада?

1) Түбән Новгород

2) Воронеж

3) Мәскәү

4) Салехард

761. Россиянең берничә торак пунктында яшәүче укучылар җирле метеостанцияләрнең һаваның июль һәм январь айларындагы уртача температурасы һәм башка климатик күрсәткечләре турындагы күпьеллык күзәтүләре мәгълүматлары белән алмашканнар. Укучылар тарафыннан тупланган әлеге мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

| Күзәтү пунктлары | Күзәтү пунктларының географик координатл | Диңгез өсте тигезлегеннән биеклеге, | Һаваның уртача температурасы, °С | | Атмосферадагы явым-төшемнәрнең бер көнен | Бер ай эчендәге аяз көннәрнең |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | январь | июль | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | ары | м | | | эчендәге уртача күләме, мм | уртача саны |
| Воронеж | 51° т.к. 39° көнч.о. | 107 | –7 | +22 | 2,10 | 2,0 |
| Саратов | 51° т.к. 46° көнч.о. | 171 | –8 | +24 | 1,38 | 2,6 |
| Новотроицк | 51° т.к. 58 көнч.о. | 202 | –12 | +22 | 1,42 | 4,7 |
| Кызыл | 51° т.к. 94° көнч.о. | 647 | –23 | +15 | 0,99 | 5,0 |

Укучылар туплаган әлеге мәгълүматларын, климатик үзенчәлекләр белән географик урыны арасындагы бәйлелекне ачыклау максаты белән анализлап чыкканнар. Укучыларның нәтиҗәләре төрлечә булган. Мәгълүматларга таянып, кайсы укучы дөрес нәтиҗә чыгарган?

1) Данила: «Торак пункт биектәрәк урнашкан саен, анда июль салкынрак».

2) Алла: «Июльдә һаваның уртача температурасы көнбатыштан көнчыгышка таба барган саен акрынлап түбәнәя».

3) Андрей: «Атмосферадагы явым-төшемнәрнең уртача

күләме көн дәвамында июль аенда уртача температура күтәрелүгә бәйле арта».

**4)** Кирилл: «Ай дәвамында аяз көннәрнең саны көнбатыштан көнчыгышка таба барганда арта».

762. Кояш кайсы шәһәрдә 23 нче сентябрьдә горизонт өстенә Мәскәү вакыты буенча барысына караганда да соңрак күтәрелә?

**1)** Воронеж

**2)** Саратов

**3)** Новотроицк

**4)** Кызыл

763. Россиянең берничә торак пунктында яшәүче укучылар җирле метеостанцияләрнең һаваның июль һәм январь айларындагы уртача температурасы һәм башка климатик күрсәткечләре турындагы күпьеллык күзәтүләре мәгълүматлары белән алмашканнар. Укучылар тарафыннан тупланган әлеге мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

| Күзәтү | Күзәтү | Һаваның | Атмосферадаг | Бер ай |
|---|---|---|---|---|

| пунктлары | пунктларының географик координатлары | уртача температурасы, °C | | ы явым-төшемнәрнең бер көн эчендәге уртача күләме, мм | эчендә ге аяз көннәрнең уртача саны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | январь | июль | | |
| Воронеж | 51° т.ш. 39° көнч.о. | –7 | +22 | 2,10 | 2,0 |
| Саратов | 51° т.ш. 46° көнч.о. | –8 | +24 | 1,38 | 2,6 |
| Орск | 51° т.ш. 59° көнч.о. | –12 | +22 | 1,42 | 4,7 |
| Кызыл | 51° т.ш. 94° көнч.о. | –23 | +15 | 0,99 | 5,0 |

Кояш кайсы шәһәрдә 23 нче сентябрьдә горизонт өстенә Мәскәү вакыты буенча барысына караганда да соңрак күтәрелә?

1) Воронеж

2) Саратов

3) Орск

4) Кызыл

764. Укучылар пунктның климат үзенчәлеге һәм географик урыны арасындагы бәйлелекне ачыклау максаты белән җыелган мәгълүматларны анализлыйлар. Укучыларның нәтиҗәләре төрлечә килеп чыга. Мәгълүматлар нигезендә кайсы укучы дөрес нәтиҗә ясаган?

| | |
|---|---|
| **1)** | Фёдор: «Пункт төньяккарак урнашкан саен, бер ай дәвамындагы аяз көннәр саны азрак». |
| **2)** | Вера: «Пункт төньяккарак урнашкан саен, анда июль аенда һава температурасы югарырак». |
| **3)** | Аида: «Көнбатыштан көнчыгышка таба хәрәкәт иткәндә, атмосферадагы явым-төшемнәрнең уртача күләме акрынлап азая». |
| **4)** | Степан: «Июль аенда җылырак булган саен, көн дәвамындагы атмосферадагы явым-төшем кими төшә». |




765. Һава торышы картасы 2012 нче елның 3 нче апреленә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый нык җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Санкт-Петербург

2) Мәскәү

3) Воронеж

4) Нарьян-Мар

766. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр циклон хакимлек иткән зонада?

1) Астрахань

**2)** Түбән Новгород

**3)** Мурманск

**4)** Элиста

---




767. Картада күрсәтелгән кайсы торак пункт антициклон хакимлек иткән зонада?

**1)** Салехард

**2)** Сургут

**3)** Чита

**4)** Ямбург

768. Һава торышы картасы 9 нчы мартта төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый нык суытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Бийск

**2)** Томск

**3)** Сургут

**4)** Красноярск

769. Һава торышы картасы 2013 нче елның 7 нче апреленә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый нык суытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Архангельск

**2)** Новосибирск

**3)** Пермь

**4)** Благовещенск

770. Картада күрсәтелгән кайсы торак пункт антициклон хакимлек иткән зонада?

**1)** Благовещенск

**2)** Красноярск

**3)** Иркутск

**4)** Магадан

771. Этна – Европаның хәрәкәттәге иң эре вулканы. Этнаның активл геофизиклар, вулканологлар игътибар белән күзәтәләр. Этна ел саен ди уяна, әмма көчле җир атылулар Сицилиядә 150 елга бер була, һәм һәр оч үзәнлектәге бер авыл утлы лава астында кала. Куркыныч янауга да карам кешеләр Этна янәшәсенә килеп урнаша торалар.

Табигать шартларының нинди үзенчәлеге, куркыныч янауга карама кешеләрне Этна янына килеп урнашырга һәм игенчелек бе шөгыльләнергә мәҗбүр итә? Ике үзенчәлеген атагыз.

Җавабыгызны аерым биттә яки бланкта языгыз, башта биремнең номе биргегез.

772. Россиянең төрле шәһәрләрендәге берничә мәктәп укучылары үзләренең географик мәйданчыкларында алып барган күзәтүләренең нәтиҗәләре белән алмашалар. 23 нче сентябрьдә кояш вакыты белән төш вакытында (барлык шәһәрләрдә дә Мәскәү вакыты) һәр шәһәрдә Кояшның горизонт өстендәге биеклеген ачыклыйлар һәм һава температурасын билгелиләр. Күзәтүләренең нәтиҗәләре түбәндәге таблицада китерелә.

| Күзәтү пунктлары | Күзәтү пунктларының географик координатлары | Кояшның горизонт өстеннән биеклеге | Һава температурасы, °С | Күзәтү вакыты (Мәскәү вакыты белән) |
|---|---|---|---|---|
| Луга | 59° т.к. 30° көнч.о. | 31° | +14 | 13 сәг. 00 мин. |
| Тверь | 57° т.к. 36° көнч.о. | 34° | +12 | 13 сәг. 24 мин. |
| Тамбов | 53° т.к. 42° көнч.о. | 37° | +15 | 13 сәг. 48 мин. |
| Волгоград | 49° т.к. 45° көнч.о. | 41° | +14 | 14 сәг. 00 мин. |

773. Кайсы шәһәрдә 22 нче июньдә көн озынлыгы иң озын булыр?

1) Луга

**2)** Тверь

**3)** Волгоград

**4)** Тамбов

774. Җыелган мәгълүматлар география дәресләрендә өйрәнелгән закончалыкны раслый?

**1)** Россиянең Европа өлешендә һава температурасы төньяктан көньякка таба хәрәкәт иткәндә күтәрелә.

**2)** Һава температурасы тәүлек дәвамында үзгәрә.

**3)** Кояшның горизонт өстеннән биеклеге көн дәвамында күзәтү вакытына бәйле рәвештә үзгәрә.

**4)** Кояшның горизонт өстеннән биеклеге экваторга якынлашканда арта.

775. Укучылар интернеттан Азия метеостанцияләрендә күп еллар дәвамында алып барылган күзәтүләр нәтиҗәсендә январь һәм июль айларында уртача һава температуралары һәм башка климатик күзәтүләр турында тупланган мәгълүматларны табып алалар Укучылар тарафыннан

тупланган әлеге мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

| Метеостанциянең исеме | Географик координатлары | Диңгез өсте тигезлегеннән биеклеге , м | Июльдә һаваның уртача температурасы, °С | Январьдә һаваның у... температу... °С |
|---|---|---|---|---|
| Тура | 64° т.к. 100° көнч.о. | 168 | +12,4 | –36,4 |
| Гарзэ | 31° т.к. 100° көнч.о. | 339 | +14,3 | –3,9 |
| Фитсанулок | 16° т.к. 100° көнч.о. | 44 | +30,1 | +24,6 |
| Паданг | 0° к. 100° көнч.о. | 3 | +26,2 | +26,3 |

Укучылар туплаган әлеге мәгълүматларын, климатик үзенчәлекләр белән географик урыны арасындагы бәйлелекне ачыклау максаты белән анализлап чыкканнар Укучыларның нәтиҗәләре төрлечә булган. Мәгълүматларга таянып, кайсы укучы дөрес нәтиҗә чыгарган?

**1)** Вадим: «Диңгез өсте тигезлегеннән югарырак булган саен, температурасы җәй көне түбәнрәк».

**2)** Оксана: «Экваторда һава температурасы ел әйләнәсендә һәрвак... югары».

| | |
|---|---|
| **3)** | Андрей: «Экваторда җәйге һәм кышкы температуралар аермасы иң аз”. |
| **4)** | Ксения: «Диңгез өсте тигезлегеннән югары булган саен, кышын һава температурасы түбәнрәк». |

776. Кайсы торак пунктта 22 нче июньдә көн озынлыгының иң дәвамлы булуы күзәтелер?

**1)** Тура

**2)** Гарзэ

**3)** Фитсанулок

**4)** Паданг




777. Картада күрсәтелгән кайсы торак пункт антициклон хакимлек иткән зонада?

1) Мурманск

2) Новосибирск

3) Тикси

4) Магадан

778. Һава торышы картасы 2013 нче елның 18 нче апреленә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый нык салкынайтып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Астрахань

**2)** Мәскәү

**3)** Омск

**4)** Төмән

779. Россиянең төрле шәһәрләрендәге берничә мәктәп укучылары җирле метеостанцияләрнең күпьеллык күзәтүләренең мәгълүматлары белән алмашалар.

Алар туплаган мәгълүматлар таблицада китерелгән.

| Күзәтү пункты | Күзәтү пунктының географик координатлары | Диңгез өсте тигезлегеннән биеклек, м | Һаваның уртача температурасы, °С | | Явым-төшемле уртача еллык көннәр саны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | июль | январь | |
| Астрахань | 46° т.к. 48° көнч.о. | –22 | +25,3 | –6,7 | 40 |
| Тамбов | 53° т.к. 42° көнч.о. | 139 | +20,0 | –10,7 | 100 |
| Мәскәү | 56° т.к. 37° | 147 | +18,5 | –10,3 | 119 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | көнч.о. | | | | |

Укучылар туплаган әлеге мәгълүматларын, климатик үзенчәлекләр белән географик урыны арасындагы бәйлелекне ачыклау максаты белән анализлап чыкканнар. Укучыларның нәтиҗәләре төрлечә булган. Кайсы укучы мәгълүматларга таянып, дөрес нәтиҗә чыгарган?

**1)** Пётр: «Көньяк-көнчыгышка киткән саен һава температурасының еллык амплитудасы зуррак».

**2)** Иван: «Көнбатышка киткән саен, июльдә эссерәк».

**3)** Мария: «Төньяк-көнбатышкарак барган саен атмосферада явым-төшемнәр сирәгрәк».

**4)** Андрей: «Пункт биегрәк урнашкан саен, атмосферада явым-төшемнәр ешрак».

780. Кояш кайсы шәһәрдә 21 нче мартта горизонт өстенә Мәскәү вакыты буенча барысына караганда да иртәрәк күтәрелә?

**1)** Астрахань

**2)** Тамбов

**3)** Мәскәү

**4)** Санкт-Петербург

781. Россиянең берничә торак пунктында яшәүче укучылар җирле метеостанцияләрнең күпьеллык күзәтүләре мәгълүматлары белән алмашканнар.

| Күзәтү пункты | Пунктның географик координатлары | Диңгез өсте тигезлегеннән биеклеге, м | Һаваның уртача температурасы, °С | | Атмосфера явым-төшемнәренең уртача еллык күләме, мм |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | июль | январь | |
| Псков | 57° т.к. 28° көнч.о. | 42 | +17,4 | – 6,9 | 628 |
| Иваново | 57° т.к. 41° көнч.о. | 111 | +18,4 | – 9,5 | 611 |
| Балахна | 57° т.к. 44° көнч.о. | 63 | +19,0 | –11,6 | 542 |
| Ижевск | 57° т.к. 53° көнч.о. | 155 | +18,7 | –13,5 | 532 |

Укучылар туплаган әлеге мәгълүматларын, климатик үзенчәлекләр белән географик урыны арасындагы бәйлелекне ачыклау максаты белән анализлап чыкканнар. Укучыларның нәтиҗәләре төрлечә булган. Мәгълүматларга

таянып, кайсы укучы дөрес нәтиҗә чыгарган?

| | |
|---|---|
| **1)** | Алексей: «Россиянең Европа өлешендә һава температурасы январьдә көньяктан төньякка таба барганда түбәнәя». |
| **2)** | Анна: «Россиянең Европа өлешендә һава температурасы январьдә көнбатыштан көнчыгышка барган саен түбәнәя». |
| **3)** | Пётр: «Торак пункт диңгез өслегеннән никадәр түбәнрәк урнашса, атмосферада явым-төшемнәр шуның кадәр күбрәк». |
| **4)** | Светлана: «Торак пунктның диңгез өслегеннән биеклеге арткан саен һава температурасы январьда түбәнәя». |

782. Россиянең Европа өлешендәге берничә торак пунктта яшәүче укучылар июль һәм январь айларында һаваның уртача температурасы турындагы җирле метеостанцияләрнең күпьеллык күзәтүләренә нигезләнгән мәгълүматлар белән алмашканнар.

Укучылар тарафыннан тупланган әлеге мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

| Пунктның атамасы | Географик координатлары | Диңгез өсте тигезлегеннән биеклеге, м | Июльдә һава температурасы, °С | Январьдә һава температурасы, °С ° |
|---|---|---|---|---|
| Николаевско | 58° т.к. 30° | 89 | +16,9 | –7,2 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| е | көнч.о. | | | |
| Бөек Новгор од | 58° т.к. 32° көнч.о. | 24 | +17,2 | –8,6 |
| Рыбинск | 58° т.к. 38° көнч.о. | 102 | +18,4 | –9,9 |
| Киров | 58° т.к. 49° көнч.о. | 165 | +18,1 | –14,2 |

Җыелган мәгълүматлар география дәресләрендә өйрәнелгән нинди закончалыкларны раслыйлар?

**1)** Россиянең Европа өлешендә һава температурасы июльдә биеклеккә бәйле түбәнәя.

**2)** Россиянең Европа өлешендә һава температурасы январьдә көнбатыштан көнчыгышка барган саен түбәнәя.

**3)** Россиянең Европа өлешендә һава температурасы июльдә төньяктан көньякка хәрәкәт иткәндә күтәрелә.

**4)** Россиянең Европа өлешендә һава температурасы январьдә биеклекә бәйле күтәрелә.

783. Кояш кайсы шәһәрдә 23 нче сентябрьдә горизонт өстенә Мәскәү вакыты буенча барысына караганда да иртәрәк күтәрелә?

1) Николаевск

2) Бөек  Новгород

3) Рыбинск

4) Киров

784. Кайсы чүлнең ясалуы салкын агымга бәйле?

1) Гоби

2) Ливия

3) Намиб

4) Кызылком




785. Картада күрсәелгән кайсы шәһәр циклон хакимлек иткән зонада?

1) Омск

2) Сыктывкар

3) Ростов-Дон

4) Элиста

786. Һава торышы картасы 2010 нчы елның 17 нче январенә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Санкт-Петербург

2) Мәскәү

**3)** Түбән Новгород

**4)** Омск




787. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр циклон хакимлек иткән зонада?

**1)** Иркутск

**2)** Салехард

**3)** Чита

**4)** Якутск

788. Һава торышы картасы 1 нче февральгә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый суытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Нарьян-Мар
2) Новосибирск
3) Чита
4) Якутск




789. Һава торышы картасы 2009 нчы елның 1 нче февраленә

төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый суытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Мәскәү

2) Новороссийск

3) Түбән Новгород

4) Санкт–Петербург

790. Кайсы шәһәр антициклон хакимлек иткән зонада?

1) Волгоград

2) Новороссийск

3) Петрозаводск

4) Элиста




791. Кайсы шәһәр антициклон хакимлек иткән зонада?

**1)** Мурманск

**2)** Оренбург

**3)** Салехард

**4)** Санкт-Петербург

792. Һава торышы картасы 2009 нчы елның 1 нче февраленә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Оренбург

**2)** Пермь

3) Новосибирск

4) Нарьян-Мар




793. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр циклон хакимлек иткән зонада?

1) Төмән

2) Салехард

3) Новосибирск

4) Петрозаводск

794. Һава торышы картасы 2010 нчы елның 7 нче февраленә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Мәскәү
2) Новосибирск
3) Пермь
4) Салехард




795. Һава торышы картасы 1 нче мартка төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Иркутск

2) Новосибирск

3) Төмән

4) Якутск

796. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр антициклон хакимлек иткән зонада?

1) Новосибирск

2) Төмән

3) Тура

4) Чита




797. Һава торышы картасы 2011 нче елның 17 нче январенә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый суытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Мәскәү

2) Омск

3) Төмән

4) Элиста

798. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр антициклон хакимлек иткән зонада?

1) Архангельск

2) Сыктывкар

3) Ростов-Дон

4) Түбән Новгород

---




799. Һава торышы картасы 2 нче мартка төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Новосибирск

**2)** Якутск

**3)** Тура

**4)** Төмән

800. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр антициклон хакимлек иткән зонада?

**1)** Новосибирск

**2)** Якутск

**3)** Тура

**4)** Төмән




801. Һава торышы картасы 2009 нчы елның 27 нче январенә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Новосибирск

**2)** Салехард

**3)** Ростов-Дон

**4)** Түбән Новгород

802. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр циклон хакимлек иткән зонада?

**1)** Архангельск

**2)** Петрозаводск

3) Ростов-Дон

4) Санкт-Петербург




803. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр циклон хакимлек иткән зонада?

1) Оренбург

2) Мурманск

3) Пермь

4) Новороссийск

804. Һава торышы картасы 2009 нчы елның 1 нче мартына төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Мурманск

**2)** Оренбург

**3)** Салехард

**4)** Санкт-Петербург




805. А пункты өчен һава температурасының еллык амплитудасын билгеләгез. Җавабыгызны сан белән языгыз.

806. А пункты климаты турындагы дөрес раслауны билгеләгез.

**1)** Март аенда атмосферадагы явым-төшемнәре июнь аендагыга караганда күбрәк.

**2)** Июль һәм августта атмосферадагы явым-төшемнәрнең уртача күләме 337 мм.

**3)** Апрель һәм сентябрьдә һаваның айлык уртача температурасы якынча бертигез.

**4)** Җәйге айларның уртача температурасы 20°С тан югары.

---

807. Стромболи – Тиррен диңгезендә Сицилия утравы һәм Апеннин ярымутравының көньяк чите арасында урнашкан утрау-вулкан. Ул Липар утраулары төркеменә керә һәм савыктыргыч ләм ванналары алырга килүче туристларның яраткан ял урыннары булып тора. Утрауда вулкан атылу гадәти күренеш булып тора, кайбер очракларда алар хәтта районда паром йөрүгә дә комачауламыйлар.

Ни өчен бу районда вулканнарның еш атылуы күзәтелә?

Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремегезне номерын күрсәтегез.

808. Стромболи утравының урнашкан урынын ачыклау өчен кайсы картаны сайларга кирәк?

**1)** Азия

**2)** Төньяк Америка

**3)** Европа

**4)** Австралия

---

**Пункт А**




809. Климатограмма мәгълүматларына нигезләнеп, А пункты климаты турындагы дөрес раслауны билгеләгез.

**1)** Һаваның уртача айлык температурасы апрель һәм октябрь айларында бертигез диярлек.

**2)** Атмосферадагы явым-төшемнәрнең иң күп өлеше июльгә туры килә.

**3)** Һаваның айлык уртача температурасы уңай күрсәткечкә генә ия.

**4)** Атмосферадагы явым-төшемнәрнең еллык уртача күләме 600 мм дан артмый.

810. Климатограммадан файдаланып, һава температурасының А пункты өчен, еллык амплитудасын билгеләгез. Җавабыгызны саннар белән языгыз.




811. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр циклон хакимлек иткән

зонада?

**1)** Омск

**2)** Петрозаводск

**3)** Салехард

**4)** Оренбург

812. Һава торышы картасы 13 нче февральгә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы бар?

**1)** Архангельск

**2)** Оренбург

**3)** Мәскәү

**4)** Салехард

**Пункт Z**




813. Климатограмма мәгълүматларыннан файдаланып, **Z** пункты климаты турындагы дөрес раслауны билгеләгез.

**1)** Һаваның уртача айлык температурасы мартта һәм октябрь айларында бертигез диярлек.

**2)** Атмосферадагы явым-төшемнәрнең иң күп өлеше июльгә туры килә.

**3)** Һаваның айлык уртача температурасы уңай күрсәткечкә генә ия.

**4)** Атмосферадагы явым-төшемнәрнең еллык уртачакүләме 900 мм дан артмый.

814. Климатограмма мәгълүматларыннан файдаланып, һава

температурасының **Z** пункты өчен, еллык амплитудасын билгеләгез. Җавабыгызны саннар белән языгыз.

815. Кайсы шәһәрдә 22 нче июньдә көннең озынлыгы иң кыска?

**1)** Любань

**2)** Иваново

**3)** Кирсанов

**4)** Элиста




\

816. Һава торышы картасы 1 нче февральгә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

1) Нарьян-Мар

2) Салехард

3) Новосибирск

4) Якутск

817. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр антициклон хакимлек иткән зонада?

1) Нарьян-Мар

**2)** Салехард

**3)** Новосибирск

**4)** Чита

818. 12 нче сентябрьдә Индонезия яр буйларында координаталары 3° т.к. 98° көнч.о. булган ноктада Рихтер шкаласы буенча 8,4 балл көчле җир тетрәү була, шуның артыннан ук берничә тапкыр җир асты селкетүләре кабатлана. Әлеге стихия нәтиҗәсендә кимендә 17 кеше һәлак була. Өч метрлы дулкын Суматра утравындагы балыкчылар поселогына китереп бәрә, ул йөзләгән торак йортларны җимерә, 90 якын кеше зыян күрә.

Поселокны җимергән әлеге дулкын ничек дип атала?

819. Ни өчен бу районда җир тетрәүләр еш була?

Нигезләнгән җавабыгызны аерым биткә языгыз, башта биремнең номерын күрсәтегез.




820. Климатограмма мәгълүматларыннан файдаланып, А пункты өчен һава температурасының еллык амплитудасын билгеләгез. Җавабыгызны сан белән языгыз, климаты турындагы дөрес раслауны билгеләгез.

821. Климатограмма мәгълүматларыннан файдаланып, А пунктының климаты турындагы дөрес раслауны билгеләгез.

**1)** Октябрь аенда һаваның айлык уртача температурасы апрельгә караганда югарырак.

**2)** Декабрь аенда явым - төшемнәр март аена караганда күбрәк була.

**3)** Уртача айлык һава температурасы бары тик уңай

| | |
|---|---|
| | күрсәткечкә ия. |
| **4)** | Явым - төшемнәрнең уртача еллык күләме 2000 мм дан артып китә. |
| | |




822. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр антициклон хакимлек иткән зонада?

1) Иркутск

2) Улан-Удэ

3) Чита

**4)** Магадан

823. Һава торышы картасы 20 нче августка төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Магадан

**2)** Петропавловск-Камчатка

**3)** Благовещенск

**4)** Чита

824. Американың Калифорния штатында 6,5, магнитудалы җир тетрәү була. Ул шактый матди зыян салса да, корбаннар булмый. Җир терәүдән аеруча Гумбольдт шәһәре зыян күрә, ул Сан-Францискодан төньякка 400 км да урнашкан.

Ни өчен АКШның көнбатыш ярларында даими рәвештә җир тетрәү ихтималы зур?

Җавабыгызны аерым битләргә яки бланкларга языгыз, башта биремегезнең номерын языгыз.




825. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр циклон хакимлек иткән зонада?

1) Томск

2) Оренбург

3) Петрозаводск

4) Төмән

826. Һава торышы картасы 4 нче январьгә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне һава температурасының күтәрелү ихтималы зур?

1) Архангельск

2) Санкт-Петербург

**3)** Калининград

**4)** Омск

827. Япон халкына вулканнар җирендә яшәү язмышы төшкән. Японлылар мең еллар дәвамында “ут тавы” на якын яшиләр. Илдә, килеп чыгышы ягыннан вулкан булган, 250 тау бар, шуларның 108е актив вулканнар. Даими рәвештә вулкан ату куркынычы, вулкан ату китергән сынаулар, аларда бик үзенчәлекле милли сыйфатлар формалаштырган.

Япония территориясендә вулканнарның күп булуы нәрсә белән аңлатыла?

Җавабыгызны аерым битләргә яки бланкларга языгыз, башта биремегезнең номерын языгыз.

828. Россиянең берничә торак пунктында яшәүче укучылар җирле метеостанцияләрнең июль, январь айларында һаваның уртача температурасы турындагы күпьеллык күзәтүләре мәгълүматлары белән алмашканнар. Укучылар тарафыннан тупланган әлеге мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

| Күзәтү пункты | Пунктның географик координатлары | Диңгез өсте тигезлегеннән биеклеге, м | Һаваның уртача температурасы, °С | | Атмосфера явым-төшем булган көннәрнең еллык саны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | июль | январь | |
| А | 49° т. к. 54° көнч. о. | 121 | + 21,9 | – 14,8 | 80 |
| Б | 53° т. к. 51° көнч. о. | 53 | + 20,6 | – 13,2 | 94 |
| В | 56° т. к. 47° көнч. о. | 83 | + 19,8 | – 12,8 | 125 |
| Г | 56° т. к. 42° көнч. о. | 118 | + 18,3 | – 9,7 | 110 |

Укучылар туплаган әлеге мәгълүматларын, климатик үзенчәлекләр белән географик урыны арасындагы бәйлелекне ачыклау максаты белән анализлап чыкканнар Укучыларның нәтиҗәләре төрлечә булган. Мәгълүматларга таянып, кайсы укучы дөрес нәтиҗә чыгарган?

**1)** Вова: «Көнбатышка таба июльдә кызуырак».

**2)** Саша: «Көньяк – көнчыгышка барган саен температураның еллык амплитудасы югарырак».

3) Дарья: «Пунк никадәр югарырак урнашкан булса, явым-төшемнәр шулкадәр ешрак».

4) Света: «Төньяк – көнбатышка барган саен, явым-төшемнәр сирәгрәк».

829. Кайсы торак пунктта 22 нче июньдә көн озынлыгы иң кыска?

**1)** А

**2)** Б

**3)** В

**4)** Г




830. Һава торышы картасы 17 нче январьгә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында икенче көнне шактый җылытып җибәрү ихтималы зуррак?

**1)** Санкт-Петербург

**2)** Мәскәү

**3)** Түбән Новгород

**4)** Омск

831. Кайсы шәһәр циклон хакимлек иткән зонада?

**1)** Омск

| |
|---|
| **2)** Сыктывкар<br><br>**3)** Ростов-на-Дону<br><br>**4)** Элиста |
| |




832. Һава торышы картасы 17 нче январьгә төзелгән. Картада бирелгән шәһәрләрнең кайсында алдагы көндә шактый суытып җибәрү ихтималы зур?

1) Мәскәү

2) Омск

3) Төмән

4) Элиста

833. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр антициклон хакимлек иткән зонада?

1) Архангельск

2) Сыктывкар

3) Ростов-Дон

4) Түбән Новгород

834. Россиянең көньягындагы бер мәктәп укучылары 21 нче мартта шәһәр читендәге бер биек булмаган тау башына компас буенча көнбатыштан көнчыгышка таба хәрәкәт итеп, походка барганнар. Алар ярты сәгать саен кыска тукталышлар ясаганнар, шул вакытта һава температурасын, атмосфера басымын үлчәгәннәр һәм Кояшның горизонт өстеннән биеклеген

билгеләгәннәр. (Маршрутның тукталыш нокталары куелган схемасы рәсемдә күрсәтелгән).




Аларның күзәтүләре биргән нәтиҗәләр түбәндәге таблицада бирелә.

| Нокта № | Күзәтү вакыты | Һава температурасы, °С | Атмосфера басымы, мм тр. б. | Кояшның горизонт өстеннән биеклеге |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 9 с. 00 мин. | +10 °С | 750 | 16° |
| 2 | 9 с. 30 мин. | +11 °С | 740 | 20° |
| 3 | 10 с. 00 мин. | +12 °С | 730 | 24° |
| 4 | 10 с. 30 мин. | +13 °С | 720 | 28° |
| 5 | 10 с. 55 мин. | +14 °С | 710 | 32° |

Таблицадагы мәгълүматлар география дәресендә өйрәнгән кайсы закончалыкны раслыйлар?

| | |
|---|---|
| **1)** | Климатның континентальлеге көнбатыштан көнчыгышка юнәлешендә арта. |
| **2)** | Һава температурасы биеклеккә бәйле рәвештә түбәнәя. |
| **3)** | Кояшның биеклеге урынның географик киңлегенә бәйле үзгәрә. |
| **4)** | Атмосфера басымы биеклеккә бәйле рәвештә төшә. |

835. Россиянең берничә торак пунктында яшәүче укучылар җирле метеостанцияләрдән 2013 нче елның 5 нче февралендә алынган мәгълүматлар белән алмашканнар. Алар җыйган мәгълүматлар түбәндәге таблицада чагылдырылган.

| Пунктның атамасы | Географик координатлары | Көн озынлыгы | Кояшның төш вакытында горизонт өстеннән биеклеге | Һаваның тәүлеклек уртача температурасы |
|---|---|---|---|---|
| Воронеж | 51° т. к. 39° көнч.о. | 9 ч. 24 мин. | 22,5° | –1 °С |
| Казан | 55° т.к. 49° көнч.о. | 8 ч. 57 мин. | 18,6° | –3 °С |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Киров | 58° т.к. 50° көнч.о. | 8 ч. 33 мин. | 15,6° | –2 °C |
| Вологда | 59° т.к. 39° көнч.о. | 8 ч. 27 мин. | 14,9° | –6 °C |

Укучылар туплаган әлеге мәгълүматларны алынган характеристикалар арасындагы бәйләнешне ачыклау максаты белән анализлыйлар. Укучыларның нәтиҗәләре төрлечә булган. Мәгълүматларга таянып, кайсы укучы дөрес нәтиҗә чыгарган?

**1)** Наташа: "Көнчыгыштан көнбатышка таба хәрәкәт иткәндә, Кояшның горизонт өстеннән биеклеге кими.

**2)** Света: «Көньяктан төньякка хәрәкәт иткәндә, көннең озынлыгы арта».

**3)** Саша: «Төньяктан көньякка хәрәкәт иткәндә, Кояшның горизонт өстеннән биеклеге арта».

**4)** Миша: «Көнбатыштан көнчыгышка таба хәрәкәт иткәндә, һава температурасы төшә».




836. Һава торышы картасы 10 нчы январьга төзелгән. Бирелгән шәһәрләрнең кайсында алдагы көндә шактый суытып җибәрү ихтималы зур.

**1)** Ленск

**2)** Курган

**3)** Чита

**4)** Бийск

837. Картада күрсәтелгән кайсы шәһәр антициклон хакимлек иткән зонада?

**1)** Курган

**2)** Новосибирск

**3)** Салехард

**4)** Якутск